# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Җир асты байлыклары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 22 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Җир асты байлыклары турында" 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 19 статьяның беренче өлешендә:
а) дүртенче абзацта "һәм аларның саклanyшын" сүзләрен төшереп калдырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
"кыйммәтле һәм хәвефле йөкләрнең, геологик, маркшейдерлык һәм башка документларның, махсус корреспонденциянең, шулай ук дәүләт серенә кертелгән белешмәләреннән торган чыганаклары булган йөкләрнең саклanyшын.";

3) 93 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"93 статья. **Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, алардан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан күзәтү**

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, алардан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан күзәтү бурычлары җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан Россия Федерациясе халыкара

шартнамәләре, җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, алардан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган стандартлар (нормалар, кагыйдәләр) таләпләрен бозуларны кисәтүдән, ачыклаудан һәм булдырмаудан гыйбарәт.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, алардан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан күзәтү вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары (федераль дәүләт күзәтүчелеге) һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (региональ дәүләт күзәтчелеге) тарафыннан аларның компетенцияләре чикләрендә законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, алардан нәтиҗәле файдалануны һәм аларны саклауны дәүләт тарафыннан күзәтүне гамәлгә ашыруга, юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны тикшерүләрне оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.";

4) 97 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"97 статья. **Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне имин алып баруны дәүләт тарафыннан күзәтү**

Җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне имин алып баруны дәүләт тарафыннан күзәтү (алга таба – тау эшләре дәүләт күзәтчелеге) бурычлары җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан яисә җир асты байлыкларыннан файдаланучылар файдалануына бирелгән җир асты кишәрлекләрендә эшләр башкаручы затлар тарафыннан җир асты байлыклары турындагы Россия Федерациясе законнары белән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган стандартлар (нормалар, кагыйдәләр) белән билгеләнгән җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне имин алып бару, аларның халыкка, әйләнә-тирә мохиткә, биналарга һәм корылмаларга зарарлы йогынтысын кисәтү һәм бетерү, шулай ук җир асты байлыкларын саклау буенча таләпләрне бозуларны кисәтүдән, ачыклаудан һәм булдырмаудан гыйбарәт.

Тау эшләре дәүләт күзәтчелеге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2012 елның 13 гыйнвары
№ 6-ТРЗ